ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» һәм «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 16 февралендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы составына керүче «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» һәм «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен әлеге Законга кушымта нигезендә үзгәртергә.


**2 статья**

«Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (II өлеш); 2008, № 12 (VII өлеш); 2010, № 12 (I өлеш); 2012, № 1; 2013, № 7; 2014, 12 (VII өлеш); 2015, № 10 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче
муниципаль берәмлекләрнең чикләре
<u>КАРТА-СХЕМАСЫ</u>

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлегенең һәм аның
составындагы муниципаль берәмлекләрнең
территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның
статусы турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- муниципаль район чиге
- тоташу ноктасының тәртип саны
- 10 -җирлекләренең чикләре һәм аларның сан белән билгеләнеше
- торак пунктлар
- муниципаль районның административ үзәге
- җирлекнең административ үзәге

Муниципаль районның
чиктәш чикләре тасвирламасы

| | |
|---|---|
| 41(9)-4(10) | - Чуваш Республикасы, Марий Эл Республикасы |
| 4(10)-9(43) | - Биектау муниципаль районы |
| 9(43)-11(40) | - Казан шәһәре муниципаль берәмлеге |
| 11(40)-34(39) | - Югары Ослан муниципаль районы |
| 34(39)-41(9) | - Кайбыч муниципаль районы |

«Зеленодольск муниципаль районы»
муниципаль берәмлеге составына керүче
шәһәр һәм авыл җирлекләре

| Карта-схемадагы № | Муниципаль берәмлек |
|---|---|
| 1 | Зеленодольск шәһәре |
| 2 | Васильево шәһәр тибындагы поселогы |
| 3 | Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы |
| 4 | Әйшә авыл җирлеге |
| 5 | Акъегет авыл җирлеге |
| 6 | Бишнә авыл җирлеге |
| 7 | Олы Ачасыр авыл җирлеге |
| 8 | Большие Ключи авыл җирлеге |
| 9 | Олы Карагуҗа авыл җирлеге |
| 10 | Олы Шырдан авыл җирлеге |
| 11 | Олы Яке авыл җирлеге |
| 12 | Күгәй авыл җирлеге |
| 13 | Күгеш авыл җирлеге |
| 14 | Мамадыш-Әкил авыл җирлеге |
| 15 | Мулла Иле авыл җирлеге |
| 16 | Түбән Урысбага авыл җирлеге |
| 17 | Новопольский авыл җирлеге |
| 18 | Норлат авыл җирлеге |
| 19 | Октябрь авыл җирлеге |
| 20 | Осиново авыл җирлеге |
| 21 | Раифа авыл җирлеге |
| 22 | Рус Әҗиле авыл җирлеге |
| 23 | Свияжск (Зөя) авыл җирлеге |
| 24 | Өтәшкә авыл җирлеге |

»;

2) 3 нче кушымтада:

а) дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге Свияжск (Зөя) авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Свияжск (Зөя) авыл җирлеге һәм «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урында Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогыннан 4,7 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 478895,06, Y = 1273220,75 координаталы 23 нче тоташу ноктасыннан алып 4,4 км көньяк-көнчыгышка таба Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге, Свияжск (Зөя) авыл җирлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Васильево шәһәр тибындагы поселогыннан 2,6 км көньякта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан 17 нче тоташу ноктасына кадәруза.»;

б) тугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге чиге «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 1,8 км төньяк-көнбатышка таба, 7,4 км көнбатышка таба, 350 м төньякка таба 53 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

3) 5 нче кушымтаның бишенче һәм алтынчы абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә «Зеленодольск шәһәре», «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре һәм Свияжск (Зөя) авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогыннан 4,7 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 478895,06, Y = 1273220,75 координаталы 23 нче тоташу ноктасыннан алып Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 1,8 км төньяк-көнбатышка таба, 7,4 км көнбатышка таба, 350 м төньякка таба 53 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге чиге Свияжск (Зөя) авыл җирлеге белән чиктәш җирдә «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге, Свияжск (Зөя) авыл җирлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урында Свияжск (Зөя) авылыннан 1,1 км көньяк-көнчыгышта урнашкан X = 472689,99, Y = 1277303,41 координаталы 21 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 7,8 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, утрауларны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.»;

4) 27 нче кушымтаның дүртенче һәм бишенче абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Свияжск (Зөя) авыл җирлеге чиге «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 21 нче тоташу ноктасыннан алып төньяк-көнбатышка таба, сынык сызык ясап, 7,8 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап, утрауларны кисеп үтеп, төньяк-көнчыгышка таба 1,8 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буенча «Зеленодольск шәһәре», «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлекләре һәм Свияжск (Зөя) авыл җирлеге чикләре тоташкан урында Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогыннан 4,7 км төньяк-көнчыгышта Куйбышев сусаклагычы акваториясендә урнашкан X = 478895,06, Y = 1273220,75 координаталы 23 нче тоташу ноктасына кадәр уза.

Свияжск (Зөя) авыл җирлеге чиге «Зеленодольск шәһәре» муниципаль берәмлеге белән чиктәш җирдә 23 нче тоташу ноктасыннан алып көньяк-көнчыгышка таба 4,4 км Куйбышев сусаклагычы акваториясе буйлап 17 нче тоташу ноктасына кадәр уза.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.


Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан,Кремль
2017 ел, 22 февраль
№ 8-ТРЗ

«Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» һәм «Свияжск (Зөя) авыл җирлеге» муниципаль берәмлекләренең территорияләре чикләрен үзгәртү һәм «Зеленодольск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законына
кушымта

Үзгәрешләрне исәпкә алып,
муниципаль берәмлекләр чикләренең
КАРТА-СХЕМАСЫ




Шартлы билгеләр

- Татарстан Республикасы чиге
- Зеленодольск муниципаль районы чиге
- муниципаль берәмлекләр чикләре
- А-Б - «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлегенең һәм Свияжск (Зөя) авыл җирлегенең уртак чиге
- җирлекләрнең административ үзәкләре
- торак пунктлар
- Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе составына кертелүче Зеленодольск муниципаль районының Свияжск (Зөя) авыл җирлеге территориясе
- Зеленодольск муниципаль районының Свияжск (Зөя) авыл җирлеге территориясе составына кертелүче Зеленодольск муниципаль районының «Карамалы Тау шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясе